# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№1 Сентябрь 2023 ел*

ГОД ПЕДАГОГА И НАСТАВНИКА 2023 УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ



### Мәктәбемне сагындым

Җәйге ялны мин бик зарыгып көтеп алдым.Озын уку елыннан соң, без җәй көне дусларым белән рәхәтләнеп уйнадык. Әни белән болынга җиләк җыярга бардык. Мин бакчада үскән җиләк – җимешләрне җыярга булыштым. Сулар сиптем, чүпләр утадым.

Әти, мин һәм энем белән су буена балык тотырга бардык.Андагы тынлык, матурлык, кошлар сайравы миңа бик ошады.

Әлеге җәй минем хыялымны да тормышка ашырды. Мин “Шаян-тв” каналына алып баручы булып эшкә урнаштым. Съемкаларга бару, операторлар белән эшләү миңа бик ошый.Тапшыру әзер булгач, үзеңне телевизордан карау бик рәхәт.

Без быел җәй гайләбез белән Анапа шәһәренә ял итәргә бардык. Юлда барганда күп кенә шәһәрләрне үттек, алар белән таныштык, матурлыкларына сокландык. Кара диңгез безне кояшлы, матур көне белән каршы алды. Анда үскән җимешләрнең төрлелеге, күплеге мине таң калдырды.Тәмнәре дә бөтенләй башкача.

Минем җәйге ялым бик күңелле узды. Ләкин ял никадәр рәхәт һәм кызыклы булса да, мин каникулда сыйныфташларны, укытучыларны, мәктәбемне бик сагындым...

**4 нче сыйныф укучысы Галәвиева Алия**



**Кадерле беренче сыйныф укучылары, төкле аягыгыз белән. Уңышлар Сезгә!**

### Җәй – хезмәт чиреге

Җәйге каникуллар тәмам булды, җәйне - хезмәт чиреге дип әйтсәк тә, дөрес булыр. Укучылар тәҗрибә участогында тырышып эшләделәр, дару үләннәре җыйдылар. Ә аерым укучылар күмәк хуҗалыкларда хезмәт куйды. Хезмәткә өйрәнү ул җаваплылыкны арттыра, мөстәкыйльлек тәрбияли. Башкарган эшнең нәтиҗәсен күрү дә күңелле. Егетләр башкарган хезмәтләре турында классташларын да таныштырдылар. Аларның һәркайсы эшләгән эшеннән канәгать. Шигапов Гадел: икенче ел инде, җәйге чорда Тукай хуҗалыгында ындырда эшләдем. Июньнән үк эшли башладым, башта агрегатларның төзеклеген тикшердек, сушилка чистарттык. 23 июльдән уборка башланды, анда инде көнгә 10 нан артык сәгать эшли башладык. Минем вазыйфалар ашлыкның дымлылыгын тикшерү, бункер бушату. Август ахырына кадәр күп ашлык кайтты, көннәр эссе булса да тырышып эшләдек. Уборка тәмамлангач та, орлык хәзерләүдә булдым. Башкарган эшнең нәтиҗәсе буенча, хезмәт хакы түләнде, мин эшемне яратып башкардым. Закиров Илхам: мин ООО агрофирма “Уңыш” күмәк хуҗалыгында комбайнчы ярдәмчесе булып эшләдем. Мин дә икенче ел инде, бу эшне бик теләп башкардым. Ике ай дәвамында кырда булдык. Комбайнның төзеклеген карап тору мөһим, төзәтү ремонт буенча да күп эшкә өйрәндем. Үземдә комбайнны яхшы итеп йөртә алам. Эш дәверендә мин әтинең уң кулы, чын ярдәмчесе булдым. Ул мине гел өйрәтеп, мактап та алды. Киләчәктә бу һөнәрне тагын да дәвам итәрмен. Бариев Фәнил: җәйге чорда мин Әтнә терлекчелек фермасы территориясендә төрле эшләр башкардым. Чистарту, печән чабу, опилка кертү, терлек ласларын җыештыру кебек эшләр. Өлкәннәр безнең эштән канәгать булдылар. Мин Руслан белән бергә эшләдем. Бергә эшләдек тә, ял да иттек. Башкарган хезмәт өчен хезмәт хакы алу ошады.

Агачны яфрак, кешене хезмәт бизи дигән әйтем бар. Хезмәтне ярату, яшьтән эшләп үсү авыл баласына бик таныш. Егетләр киләчәктә һөнәр сайлап, кайда гына эшләсәләр дә, үз эшләренең осталары булсыннар , хезмәтне яратсыннар, уңышлар телим аларга.

**Сыйныф җитәкчесе Ганиева Ләйсән**



16 сентябрьдә гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары арасында « Татарстан кроссы - 2023» узды. Укучыларыбыз Газизов Сәйдәш һәм Абдуллина Ивилина икенче урыннарны алдылар.



## Авылымның яме - чишмәләрдә

Һәр кеше Туган җирен яратырга тиеш, дибез. Ә яратыр өчен белергә, күзең белән күрергә дә кирәк бит. Туган авылыбыз буйлап, бергәләп күптән йөргән юк иде. Татар теле дәресендә инша язу максаты белән, без, 7 нче сыйныф укучылары, көзге табигатькә экскурсиягә чыктык.

Әйе, җиһанда матур җирләр, кала-салалар бик күп, ләкин туган авылың, кендек каның тамган туган туфрак барыннан да газизрәк, изгерәк, чөнки ул - бердәнбер. Безнең Күәм авылының мактанырлык чишмә-болыннары бар.

Авыл буйлап барганда урам исемнәре белән таныштык.Җәмилә һәм исемсез бер чишмәгә бардык. Исемсез дигәне укытучы Булат абыйлар каршында .

Чишмәләр - табигать ананың йөрәк тибеше, ә күлләр аның күзләре диләр. Еракларга киткән балаларын тилмереп көткән ул күзләр түземлекләре беткәч, йомыла башлый, кибә, чишмәләр дә җырларыннан туктап, тынып кала икән. Һәр авылның үз чишмәсе. Аларның күбесе, кызганыч, бүген инде кирәкмәгәнлекләрен белгәнгә, челтерәвеннән туктап, таш-ком астында күмелеп калган. Су өйгә кадәр кергән, кирәк чагында кранны гына борасы. Ә безнең әбиләр, әниләр иңендәге көянтәләр дә күптән инде мичләрдә янгандыр. Ә чишмә суы тәмле, саф, йомшак. Җәмилә- чишмә коесыннан чиләк белән су алып карау безгә кызык булды. Битләрне юдык.Әйләнә-тирәдә бөдрә таллар безгә күләгә ясады. Чишмә буе саф һавасын сулап сөйләшеп тә утырдык, истәлеккә фотога да төштек.

Һәркем үз авылын яратырга, аңа кулыннан килгән кадәр ярдәм итәргә бурычлы. Туган авыл ул әни шикелле. Сине үстергән, кеше иткән. Син дә аңа рәхмәтле булырга тиешсең. Безгә дә үскәч, чишмәләрне карап, чистартып торырга, чишмә буенда бергәләшеп очрашып, хәлләребезне белеп яшәргә кирәк.

Ә аның өчен тырышып укырга, әхлаклы булып үсәргә тиешбез.

**Гатауллина Лилия, Галимҗанова Әдилә, 7 сыйныф.**

## Кая очтың җәй?

Хәтерлим әле, 31 нче май иде... Җәй килеп ята, алда өч ай каникуллар. Рәхәт! Күзләремне йомам. Ачсам! Ни бу? 31 нче август! Җәй үтеп тә киттемени? Сизелмәде дә!

Монысы, әлбәттә, бераз шаяру иде. Сизелде ул. Әмма аз булды шикелле. Җилләр белән куышып велосипедта чабулар, энем Айрат белән уйнаулар... Җәй буе уйнап кына йөргән дип уйламагыз. Әти-әниемә дә булыштым, ансыз буламыни! Ышанмасагыз, үзләреннән сорагыз. Әле дә мактыйлар!

Көз житүгә мәктәпкә йөгердем. Тырышып укып, белемнәр алып, вакыт машинасы уйлап табасым килә! Аны уйлап тапсам, ул мине һәрчак 31 нче май тирәсендә генә йөртер иде. Кызык бит! Яшисең, яшисең, алда һаман да өч ай каникул! Менә шулай!

**Батталов Аяз, 3 сыйныф**



## Уелып калган хатирә

Минем быелгы җәйге каникулым күңелле һәм файдалы үтте. 26 нчы майда без сыйныфыбыз белән экскурсиягә бардык.Әтнә районы Бәрәскә авылында урнашкан “Ак мәчетне”карап уздык. Анда урнашкан тарихи музейга кердек. Экспонатларга, хәзрәтнең сөйләвенә мөкиббән китеп кайттык. Шул ук вакытта, без Шиһабетдин Мәрҗәни музейена бардык. Аның тормыш юлы һәм белемле булуга нинди адымнар ясавын куреп,танышып кайттык. Мәктәп белән “Ашыт” буена походка бардык. Анда без класс белән шашлык,бәрәңге пешердек.Бергәләп җыелып ашадык. Әлбәттә куркынычсызлык кагыйдәләрен онытмадык.Табигать кочагында көне буе күмәк уеннар уйнап, җырлап, биеп рәхәтләнеп күңел ачып кайттык.

Сабантуй бәйрәменә бию өйрәнергәдә өлгердек. Аннары без бу бию не, милли бәйрәмебездә күрсәттек. Шул ук бәйрәмдә ГТО нормативлары да тапшырдык әле. Быелгы җәйдә безнең районда “Чулпан” лагеры ачылды. Анда без 7 көн ял итеп кайттык. Лагерьда төрле чаралар, беренчеләр оешмасы тарафыннан оештырылган флэшмоблар, төрле вәкилләр белән очрашулар куңелдә якты хатирә калдырды.

Казан шәһәренә сәяхәтем, туган ягым Мөслим районына барып килүем мина быелгы җәйге ялны тагыда файдалы итте. Вакытында дару үләннәрендә , җиләкләрнедә, мәктәп участогында отработканыда эшләү мина рәхәтлек бирде. Мин быелгы җәйге ялдан кәнәгать калдым.

**Мирхазианова Азалия 8 нче сыйныф**

## Халык сынамышлары

-Сентябрь җылы һәм коры булган саен, кыш соңрак килә.

-Сентябрь салкын булса, кышын кар тизрәк эри, яз тизрәк килә.

-Сентябрьдә кырмыскалар үлән өстендә чабышса, кар тирән булып ятар. Астан йөрсә - кыш озын булыр.

-Торналар өстән очса, матур, җылы көз озак торыр.

## Яңалыклар

-Композитор, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Әгъзам (Азантин) Нуретдин улы Фәттах (Фәттахетдинов)ның тууына 100 ел (1923– 2013)

-Тарихчы, нумизмат, археолог, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, Татарстанның Дәүләт премиясе лауреаты Әзһәр Гатаулла улы Мөхәммәдиевнең тууына 90 ел (1933–2018)

-Әдәби тәрҗемәче, язучы Гөлсем (Өммегөлсем) Даут кызы Мөхәммәдованың тууына 120 ел (1903–1988)



**Кроссворд чишәбез**